БАЛТАСИН РАЙОНЫЙ
ИСПОЛНИК КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЛАР

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

"17" 04 2023 ел № 136

Җирлек территориясе өстендә авиация эшләре, парашют белән сикерүләр, һава судноларының күрсәтү очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, тагылма аэростатларны күтәрүне башкару өчен рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан транспорт прокуратурасының 2023 елның 14 мартындагы 23/1-12-2023 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясе һава кодексы» 1997 елның 19 мартындагы 60 номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 123 номерлы карары белән расланган җирлек территориясе өстендә авиация эшләре, парашют белән сикерүләр, һава судноларының күрсәтү очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, тагылма аэростатларны күтәрүне башкару өчен рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендә һәм алга таба текст буенча «пилотсыз очу аппаратлары» сүзтезмәсен «пилотсыз һава суднолары (максималь очыш массасы 0,25 килограммнан ким булган пилотсыз һава судноլары очышларыннан тыш)» сүзтезмәсенә алмаштырырга;

1.2. 1.5.1 статьяның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Пилотсыз һава судносы - һава судносы бортында булмаган пилот (тышкы пилот) тарафыннан идарә ителә торган, очу вакытында контрольдә тотыла торган һава судносы».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов